**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**18.07.2023 ел** **№ 933**

## Чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставының 80 статьясындагы 8 пункты, Биектау муниципаль районы Советының 2019 елның 17 апрелендәге 279 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәнең 17 статьясы нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Биектау муниципаль районының кушымтада бирелгән чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектын төзү тәртибен расларга (алга таба - Тәртип) (1 нче кушымта).

2. 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына муниципаль район бюджеты проектын төзегәндә түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) Тәртипнең 5 пунктында каралган график «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ тарафыннан, район башкарма комитеты белән килештереп, 2023 елның 1 июленнән дә соңга калмыйча раслана;

б) Биектау муниципаль районы бюджет ассигнованиеләрен бүлү, чыгым йөкләмәләре күләме һәм структурасы, Тәртипнең 3 пунктындагы «б» һәм «г» пунктчаларында, 8 пунктында, 12 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында каралган бюджет ассигнованиеләренең иң чик күләмнәрен проектлау буенча тиешле тәкъдимнәр 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына муниципаль район бюджеты акчалары төп бүлүчеләре һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ тарафыннан формалаштырыла.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 18 июле 933 нче
номерлы карарына 1 нче кушымта

**ЧИРАТТАГЫ ФИНАНС ЕЛЫНА ҺӘМ ПЛАН ЧОРЫНА БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БЮДЖЕТЫ ПРОЕКТЫН ТӨЗҮ ТӘРТИБЕ**

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Биектау муниципаль районы (алга таба - муниципаль район) бюджет проектын чираттагы финанс елына һәм план чорына төзегәндә Башкарма комитет:

а) чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль районның бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен эшли һәм хуплый;

б) чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район икътисады эшчәнлегенең сценар шартларын, муниципаль районның социаль-икътисадый үсеш фаразының чираттагы финанс елына һәм план чорына төп параметрларын, муниципаль районның чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын эшли һәм хуплый;

в) чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджетының төп характеристикаларын, шулай ук муниципаль районның гамәлдәге һәм кабул ителә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре күләмен хуплый;

г) чираттагы финанс елында һәм план чорында муниципаль районның кабул ителә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләрен бүлүне хуплый;

д) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ белән берлектә төп бүлүчеләр тарафыннан тәкъдим ителгән чираттагы финанс елыннан яисә план чорыннан башлап муниципаль район бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган озак сроклы максатчан программалар концепцияләрен һәм проектларын, расланган озак сроклы максатчан программаларга үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәрне, Башкарма комитет һәм төп бүлүчеләрнең озак сроклы максатчан программаларга кертелмәгән муниципаль район бюджетыннан муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында актлары проектларын карый;

е) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә муниципаль район бюджетыннан озак сроклы максатчан программаларга һәм бюджет инвестицияләренә кагылышлы өлешендә кабул ителә торган йөкләмәләрне үтәүгә муниципаль район бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен билгеләү буенча тәкъдимнәр тапшыра;

ж) озак сроклы максатчан программалар концепциясен раслый, муниципаль район бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган озак сроклы максатчан программаларны раслый һәм аларга үзгәрешләр кертә;

з) чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турында карар проектын һәм аның белән бергә тапшырыла торган Биектау

муниципаль районы Советына кертү өчен документлар һәм материалларны хуплый.

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты проектын эшләүне оештыра һәм төзи, шул исәптән:

а) чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре проектын эшли;

б) муниципаль район бюджетының төп характеристикаларын проектлый, шулай ук гамәлдәге һәм кабул ителә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә муниципаль район бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен исәпләүне гамәлгә ашыра;

в) муниципаль районның чыгым йөкләмәләре реестрын алып бара;

г) муниципаль район бюджетының бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру тәртибен һәм методикасын билгели;

д) муниципаль районның чыгым йөкләмәләре күләмен һәм (яисә) структурасын үзгәртүгә бәйле булган муниципаль хокукый актлар проектларына бәяләмәләр һәм муниципаль район бюджеты акчаларын төп бүлүчеләрнең (алга таба - төп бүлүчеләр) тәкъдимнәрен әзерли;

е) Башкарма комитетка кабул ителә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә муниципаль район бюджеты бюджет ассигнованиеләрен бүлү буенча тәкъдимнәр (тәкъдимнәргә бәяләмәләр) тапшыра, Башкарма комитет карарлары нигезендә чираттагы финанс елында һәм план чорында кабул ителә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә муниципаль район бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү проектын эшли;

ж) баш бүлүчеләргә муниципаль район бюджетының баш бүлүчеләр буенча бюджет ассигнованиеләренең иң чик күләмнәре (иң чик күләмнәре үзгәрешләре) проектларын эшли һәм җибәрә;

з) тиешле баш бүлүчеләр буенча муниципаль район бюджетының чыгым йөкләмәләре һәм бюджет ассигнованиеләре реестрларын баш бүлүчеләр тарафыннан тапшыру тәртибен әзерләү белән методик җитәкчелекне гамәлгә ашыра һәм билгели;

и) муниципаль район бюджеты керемнәренең баш администраторлары һәм муниципаль район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары белән бергә муниципаль район бюджеты керемнәре классификациясенең статьялары һәм муниципаль район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча фараз әзерли;

к) баш бүлүчеләр белән берлектә, җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән муниципаль район бюджетыннан бюджетара трансфертларны бүлүне исәпләү өчен, башлангыч күрсәткечләрне чагыштыру төзи һәм гамәлгә ашыра;

л) муниципаль алынмалар программалары проектларын, чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль гарантияләр программалары проектларын эшли;

м) агымдагы финанс елына муниципаль район бюджетының көтелгән үтәлешен бәяләүне гамәлгә ашыра;

н) чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турында карар проектын, шулай ук Биектау муниципаль районы Советына күрсәтелгән проект белән бергә тапшырылырга тиешле документларны һәм материалларны формалаштыра һәм Башкарма комитетка тапшыра.

3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты

проектын төзегәндә баш бүлүчеләр:

а) муниципаль район бюджеты акчаларын тиешле баш бүлүчеләргә каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән үтәлергә тиешле чыгым йөкләмәләре реестрларын алып баралар һәм аларны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУнә тапшыралар;

б) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУнә чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына бюджет ассигнованиеләрен бүлүгә һәм план чорының икенче елына бюджет ассигнованиеләрен тиешле баш бүлүчеләр, бүлекләр, бүлекчәләр, максатчан статьялары һәм бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре буенча бүлүгә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр тапшыра, шулай ук Башкарма комитетка - күрсәтелгән тәкъдимнәрне муниципаль район бюджетыннан озак сроклы муниципаль максатчан программаларга һәм бюджет инвестицияләренә кагылышлы өлештә;

в) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУнә бюджет ассигнованиеләрен тиешле баш бүлүчеләр буенча нигезләүләр тәкъдим итә;

г) чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына муниципаль районның чыгым йөкләмәләре күләмен һәм (яисә) структурасын үзгәртү буенча һәм план чорының икенче елына муниципаль районның чыгым йөкләмәләре күләмен һәм (яисә) структурасын үзгәртү буенча тәкъдимнәр, шул исәптән озак сроклы муниципаль максатчан программаларның концепцияләре һәм проектлары, шулай ук муниципаль район бюджетыннан бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр һәм расланган озак сроклы муниципаль һәм ведомство максатчан программаларын гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләрен үзгәртү буенча тәкъдимнәр әзерлиләр;

д) озак сроклы максатчан программаларны һәм ведомство максатчан программаларын гамәлгә ашыру турында хисаплар, шулай ук озак сроклы максатчан программаларга кертелмәгән капиталь төзелеш объектларына муниципаль район бюджетыннан бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар төзиләр;

е) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУнә чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты турында Биектау муниципаль районы Советы карары проектына аңлатма язуы әзерләү өчен кирәкле эшчәнлекнең тиешле өлкәсе мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр тапшыралар.

4. Муниципаль район бюджеты проектын төзегәндә муниципаль район бюджеты керемнәренең баш администраторлары һәм муниципаль район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ белән муниципаль район бюджетына муниципаль район бюджеты керемнәренең тиешле төрләре (төркемчәләре) һәм муниципаль район бюджеты керемнәрен финанслау чыганаклары буенча керемнәр күләмнәре фаразын әзерлиләр һәм килештерәләр.

## II. ЧИРАТТАГЫ ФИНАНС ЕЛЫНА ҺӘМ ПЛАН ЧОРЫНА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БЮДЖЕТЫ ПРОЕКТЫН ТӨЗҮНЕҢ ТӨП ЭТАПЛАРЫ

5. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ, Башкарма комитет белән килештереп, агымдагы финанс елның 1 июленә кадәр муниципаль район бюджеты проектын төзегәндә эшләнә торган карарлар, документлар һәм материаллар проектларын әзерләү һәм карау графигын раслый.

6. Башкарма комитет агымдагы финанс елының 1 августына кадәр:

а) агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына муниципаль районның социаль-икътисадый үсешенең төгәлләштерелгән фаразын карый;

б) чираттагы финанс елыннан яисә план чорыннан башлап гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителгән озак сроклы максатчан программалар концепцияләрен раслый.

7. Баш бүлүчеләр агымдагы финанс елының 15 августына кадәр Башкарма комитетка һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУнә муниципаль район бюджетыннан озак сроклы максатчан программаларга кертелмәгән капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен чираттагы финанс елыннан яисә план чорыннан башлап әзерләү һәм гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр җибәрә.

8. Баш бүлүчеләр агымдагы финанс елының 25 августына кадәр Башкарма комитетка һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУнә чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына муниципаль районның чыгым йөкләмәләре күләмен һәм (яисә) структурасын үзгәртү буенча тәкъдимнәр һәм план чорының икенче елына муниципаль районның чыгым йөкләмәләре күләмен һәм (яисә) структурасын үзгәртү буенча тәкъдимнәрне озак сроклы максатчан программалар проектлары белән, расланган озак сроклы максатчан программаларга үзгәрешләр белән һәм муниципаль район бюджетыннан бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында башка норматив хокукый актлар (карарлар) проектларына бәйле өлештә җибәрәләр.

9. Башкарма комитет агымдагы финанс елының 20 сентябренә кадәр карый:

а) чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль районның социаль-икътисадый үсеш фаразының сценар шартларын һәм төп параметрларын;

б) чираттагы финанс елына һәм план чорына салым сәясәтенең төп юнәлешләрен;

в) чираттагы финанс елыннан яисә план чорыннан башлап муниципаль районның гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен кыскарту (структураны үзгәртү) тәкъдимнәрен;

г) муниципаль район бюджетын формалаштыруның шартларын һәм төп бурычларын билгеләүче бюджет сәясәтенең төп юнәлешләрен, күрсәтелгән бюджет керемнәренең һәм чыгымнарының күләме һәм структурасының фаразлана торган үзгәрешләрен, муниципаль район бюджетының баланслылыгын, кабул ителә торган муниципаль район чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре гомуми (чикле) күләме һәм эреләтеп бүленүен;

д) чираттагы финанс елыннан яисә план чорыннан башлап муниципаль район бюджетыннан озак сроклы максатчан программаларга кертелмәгән капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләренең әзерләү һәм гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр.

10. Башкарма комитет агымдагы финанс елының 20 сентябренә кадәр:

а) чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджетының төп характеристикаларын раслый;

б) муниципаль районның кабул ителә торган чыгымнар йөкләмәләрен үтәүгә муниципаль район бюджеты бюджет ассигнованиеләренең гомуми (иң чик) күләмен бүлүне хуплый;

в) чираттагы финанс елыннан (план чорыннан) башлап гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган озак сроклы максатчан программаларны, шулай ук расланган озак сроклы максатчан программаларга кертелә торган үзгәрешләрне раслый;

г) муниципаль район бюджетыннан озак сроклы максатчан программаларга кертелмәгән капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында актлар кабул итә (актларга үзгәрешләр кертә);

д) муниципаль район бюджеты турында карар проектын әзерләү өчен кирәкле башка карарлар кабул итә.

11. Башкарма комитет агымдагы финанс елының 10 ноябреннән дә соңга калмыйча чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турында карар проектын, шулай ук Биектау муниципаль районы Советына күрсәтелгән карар проекты белән бергә кертелергә тиешле документлар һәм материалларны карый, һәм аны агымдагы финанс елының 15 ноябреннән дә соңга калмыйча Биектау муниципаль районы Советына карауга кертә.

## III. БАШКАРМА КОМИТЕТКА ТАПШЫРУ ӨЧЕН ЧИРАТТАГЫ ФИНАНС ЕЛЫНА ҺӘМ ПЛАН ЧОРЫНА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БЮДЖЕТЫ ТУРЫНДА КАРАР ПРОЕКТЫН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНА ӘЗЕРЛӘҮ

12. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ:

а) Агымдагы финанс елының 1 сентябренә кадәр җирлекләрнең финанс органнарына җирлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлар исәпләрен уздыру өчен башлангыч күрсәткечләр җибәрә;

агымдагы финанс елның 15 сентябренә кадәр ул билгеләгән тәртиптә җирлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлар исәпләрен үткәрү өчен башлангыч күрсәткечләрне чагыштыру үткәрә;

б) агымдагы елның 1 сентябренә кадәр төп бүлүчеләргә җибәрә:

агымдагы финанс елында һәм план чорының беренче елында гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә муниципаль район бюджетының бюджет ассигнованиеләренең иң чик күләмнәре үзгәрешләре проектировкаларын һәм план чорының икенче елында гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә муниципаль район бюджетының бюджет ассигнованиеләренең иң чик күләмнәре проектировкаларын;

чираттагы финанс елында һәм план чорында кабул ителә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә муниципаль район бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Башкарма комитет карарлары нигезендә бүлү проектировкаларын;

13. Агымдагы елның 15 сентябренә кадәр:

а) баш бүлүчеләр «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУнә бюджет ассигнованиеләрен чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына бүлү буенча һәм план чорының икенче елына бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы бюджеты чараларын баш бүлүчеләр буенча, Башкарма комитетка муниципаль район бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләренә (озак сроклы муниципаль максатчан программалар һәм капиталь төзелеш объектлары буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүгә кагылышлы өлештә) үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр, чыгым йөкләмәләренең планлы реестрларын һәм тиешле баш бүлүчеләрнең бюджет ассигнованиеләрен нигезләүләрен, тиешле баш бүлүчеләрнең алып баруына кертелгән мәсьәләләр өлешендә муниципаль район бюджеты турында карар проектына аңлатма язуын тапшыралар;

б) муниципаль район бюджеты керемнәренең баш администраторлары һәм муниципаль район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУнә бюджет керемнәре классификациясенең һәм муниципаль район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының тиешле төрләре (төркемчәләре) буенча хисаплар тапшыралар.

14. Башкарма комитетның икътисад бүлеге агымдагы финанс елының 15 октябренә кадәр «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУнә муниципаль районның социаль-икътисадый үсеше фаразының төгәлләштерелгән төп параметрларын тәкъдим итә.

15. Агымдагы финанс елының 1 ноябренә кадәр «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ Башкарма комитетка, алга таба Биектау муниципаль районы Советына тапшыру өчен, чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турында карар проектын, шулай ук Биектау муниципаль районы Советына күрсәтелгән проект белән бер үк вакытта тапшырылырга тиешле документларны һәм материалларны тапшыра.

Биектау муниципаль районы бюджет проектын өч еллык чорга төзү тәртибенә кушымта

## Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектын төзү һәм кабул итү графигы

Биектау муниципаль районы бюджетын чираттагы финанс елына һәм план чорына үз вакытында формалаштыру һәм раслау, Биектау муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәнең таләпләрен үтәү максатларында чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә катнашучыларның түбәндәге эш регламенты (чаралар исемлеге, аларны җаваплы башкаручылар тарафыннан үтәү сроклары) билгеләнә:

| № т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| | Биектау муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын өч еллык чорга билгеләү | | |
| 1. | Агымдагы финанс елының үткән чорында Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә якынча йомгакларын эшләү һәм агымдагы финанс елында районның социаль-икътисадый үсешенең көтелә торган йомгаклары | агымдагы финанс елының 5 июленә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге |
| 2. | Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын эшләү | агымдагы финанс елының 5 июленә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге |
| 3. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына бәяләр индекс-дефляторлары фаразы. | агымдагы финанс елының 5 июленә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге |
| 4. | Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләү | агымдагы финанс елының 5 сентябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 5. | Агымдагы финанс елында бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәрен фаразлауны һәм аларның чираттагы финанс елына һәм план чорына кертемнәрен фаразлауны исәпләү | агымдагы финанс елының 15 августына кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |

| № т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| 6. | Агымдагы финанс елында чыгымнар буенча бюджетны үтәүне бәяләү | агымдагы финанс елының 20 сентябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 7. | Бюджет акчаларын баш бүлүчеләр киселешендә Биектау муниципаль районы бюджетының чираттагы финанс елына һәм план чорына чыгымнар буенча бюджет ассигнованиеләренең якынча күләмнәрен билгеләү һәм аларны бюджет акчаларын төп бүлүчеләргә җиткерү | агымдагы финанс елының 20 сентябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| | Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәрен чираттагы финанс елына һәм план чорына формалаштыру (исәпләүләр һәм нигезләүләр белән мәгълүмат «Биектау муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУсенә тапшырыла) | | |
| 1. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына фараз параметрларын "Хезмәт хакы фонды" күрсәткече буенча Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразының төп күрсәткечләре составында һәм план чоры тәмамланганчыга кадәр фараз параметрларын килештерү. | агымдагы финанс елының 5 июленә кадәр | БМР БК җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге |
| 2. | Киләсе финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы керемнәре буенча фараз һәм бюджет проектын эшләү өчен кирәкле белешмәләр, шул исәптән: | | Россия федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча N 3 районара инспекциясе |
| 2.1. | Россия Федерациясе законнары нигезендә салым органнары администрацияли торган салымнарның, җыемнарның һәм башка мәҗбүри түләүләрнең тиешле төрләре буенча тулаем түләүләр турында мәгълүмат. | агымдагы финанс елының 15 июленә кадәр | |
| 2.2. | Салым органнары Россия Федерациясе законнары нигезендә администрацияли торган салымнарның, җыемнарның һәм башка мәҗбүри | агымдагы финанс | |

| № т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| | түләүләрнең тиешле төрләре буенча тулаем алганда түләнгән суммалар турында мәгълүмат. | елының 15 июленә кадәр | |
| 2.3. | Россия Федерациясе законнары нигезендә салым органнары тарафыннан администрацияләнә торган салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләрнең тиешле төрләре буенча тулаем салымнарны, җыемнарны, пеняларны һәм штрафларны түләтүгә срогы кичектерелгән (бүлеп бирелгән), реструктурлаштырылган һәм туктатылган бурычның, недоимканың суммалары турында мәгълүмат. | агымдагы финанс елының 15 июленә кадәр | |
| 2.4. | Биектау муниципаль районы буенча Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җирле бюджетлар керемнәрен төзи торган салым базасы һәм салымнар һәм җыемнар буенча түләүләр структурасы турында белешмәләр. | хисап елыннан соң килүче елның 15 июленә кадәр | |
| 2.5. | Агымдагы финанс елы өчен Биектау муниципаль районы бюджетына администрацияләнә торган керемнәр һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына фараз турында көтелә торган керемнәр турында белешмәләр | агымдагы финанс елының 03 августына кадәр | |
| 3. | Биектау муниципаль районы бюджетына керемнәр керүне фаразлау методикасын эшләү һәм раслау | агымдагы финанс елының 25 июленә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары |
| 4. | Финанслауның бюджеттан тыш чыганаклары исәбенә һәм партнерлык шартларында агымдагы финанс елында эксплуатациягә тапшырыла торган һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында тапшырылуга фаразлана торган объектлар исемлеге, агымдагы елда көтелә торган һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында фаразлана торган Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗәләрендәге салымнар кертемнәре күләмнәрен күрсәтеп. | агымдагы финанс елының 15 сентябренә кадәр | БМР БК җитәкчесенең төзелеш мәсьәләләре буенча урынбасары Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге |
| 5. | Устав капиталы өлешенә муниципаль район ия булган хуҗалык | агымдагы финанс | |

| № т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| | җәмгыятьләренең һәм Биектау муниципаль унитар предприятиеләренең, хисап финанс елында төп эшчәнлек төрен һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеге күрсәткечләрен күрсәтеп, тулы исемлеге. | елының 15 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районының «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ |
| 6. | Агымдагы финанс елы өчен Биектау муниципаль районы бюджетына административ керемнәрне фаразлауны һәм аларның чираттагы финанс елына һәм план чорына кертемнәрен фаразлауны бәяләү | агымдагы финанс елының 05 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары |
| 7. | Биектау муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча кертемнәрне фаразлау методикасын эшләү һәм раслау | агымдагы финанс елының 25 сентябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ. Биектау муниципаль районы Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| 8. | Федераль казначылыкка Россия Федерациясе Бюджет системасы бюджетлары керемнәре чыганаклары исемлегенә кертү өчен мәгълүмат һәм документлар җибәрү | Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән срокларда | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ. |
| 9. | Биектау муниципаль районыныж бюджет керемнәре чыганаклары реестрын төзү һәм алып бару | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Биектау муниципаль | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ. |

| № т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| | | районы норматив хокукый актларында билгеләнгән срокларда | |
| | Биектау муниципаль районы бюджеты чыгымнарын чираттагы финанс елына һәм план чорына формалаштыру | | |
| 1. | Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына финанслауны гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалары исемлеге | агымдагы финанс елының 01 июленә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге |
| 2. | Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гомумроссия база (тармак) исемлекләрендә, Татарстан Республикасы хезмәт күрсәтүләренең һәм эшләренең региональ исемлегендә чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль биремнәр проектларын формалаштыруга әзерлек максатларында хезмәт күрсәтүләрне анализлау | агымдагы финанс елының 5 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 3. | Биектау муниципаль районы бюджетының чыгым йөкләмәләрен оптимальләштерү һәм аларны карарларны кабул итү өчен Биектау муниципаль районы башкарма комитетына тапшыру тәкъдимнәре | агымдагы финанс елының 5 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 4. | Биектау муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләре буенча; муниципаль мәгариф, мәдәният, физик культура һәм спорт учреждениеләре буенча чираттагы финанс елына һәм план чорына «БАРС-МБП-Мониторинг» программа комплексында челтәр күрсәткечләре формалаштыру | агымдагы финанс елының 15 июненә кадәр (тәгәллек кертелгән күрсәткечләр 01 октябрьгә кадәр) | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5. | Бюджет акчаларын баш бүлүчеләр киселешендә чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле үзидарә органнарының штат саны турындагы белешмәләр (алдагы финанс елына, норматив санга, чираттагы финанс елына һәм план чорына проект) һәм аларны «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсенә тапшыру | агымдагы финанс елының 10 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы Советының кадрлар бүлеге |

| №<br>т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| 6. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектына ГРБСның чыгым йөкләмәләре реестрларын формалаштыру | агымдагы финанс елының 15 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 7. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль хезмәт күрсәтүләр (эшләр) киселешендә чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль биремнәр проектларын төзү һәм «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУда муниципаль учреждениеләрнең күләм күрсәткечләре буенча җыелма мәгълүмат бирү | агымдагы финанс елының 25 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 8. | Мәгариф, мәдәният, физик культура һәм яшьләр сәясәте өлкәләрендә чаралар үткәрүнең фаразлау планы һәм аларны «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсына тапшыру | агымдагы финанс елының 25 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 9. | Муниципаль учреждениеләр тарафыннан юридик, физик затларга чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү һәм аларны «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсенә тапшыру | агымдагы финанс елының 25 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 10. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль биремнәрне үтәүне финанс белән тәэмин итүгә муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә субсидияләр күләмнәрен исәпләү һәм «Биектау муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУда муниципаль учреждениеләр киселешендә җыелма мәгълүмат бирү | агымдагы финанс елының 25 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11. | Биектау муниципаль районы бюджетыннан муниципаль бюджет автоном оешмаларының башка максатларына субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе нигезендә муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә чираттагы финанс елына һәм план чорына башка максатларга субсидияләр күләмнәрен исәпләү һәм «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсенә муниципаль учреждениеләр киселешендә җыелма мәгълүмат бирү | агымдагы финанс елының 25 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |

| № т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| 12. | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының ведомство буйсынуындагы казна учреждениеләрен дә кертеп, җирле үзидарә органнары һәм казна учреждениеләре өчен бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру методикасы нигезендә чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет ассигнованиеләре ихтыяҗларын исәпләү | агымдагы финанс елының 25 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 13. | Җиткерелгән фаразланган күрсәткечләр чикләрендә чираттагы финанс елына һәм план чорына финанслауны гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программаларны финанслауга чыгымнар күләме буенча исәпләүләр һәм нигезләүләр әзерләргә һәм Биектау муниципаль районының муниципаль программалары проектларын формалаштырырга | агымдагы финанс елының 1 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр һәм муниципаль программаларның (ярдәмче программаларның) муниципаль заказчылары |
| 14. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына финанслауны гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалар проектларын килештерү | агымдагы финанс елының 15 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге<br>«Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 15. | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә чираттагы финанс елыннан һәм план чорыннан башлап гамәлгә ашыру сроклары белән Биектау муниципаль районы муниципаль программаларын раслау турында карар әзерләргә һәм раслауга кертергә | агымдагы финанс елының 01 ноябренә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге<br>Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр һәм муниципаль программаларның (ярдәмче программаларның) муниципаль заказчылары |

| № т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| 16. | «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсенә чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен кирәкле ассигнованиеләрнең фаразлана торган күләмнәре турында чираттагы финанс елына һәм план чорына, финанс-бюджет палатасы раслаган форма буенча һәр планлаштырылган елга бүлеп мәгълүмат әзерләргә һәм тапшырырга | агымдагы финанс елының 11 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| | Биектау муниципаль районы бюджеты проектын чираттагы финанс елына һәм план чорына формалаштыру | | |
| 1. | Биектау муниципаль районы бюджеты проектын чираттагы финанс елына һәм план чорына төзү | агымдагы финанс елының 29 октябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 2. | Биектау муниципаль районы Советының бюджет, салым һәм инвестиция сәясәте комиссиясе белән чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын килештерү | агымдагы финанс елының 31 октябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 3. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын карауга кабул итү турында һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында норматив хокукый акт проектын әзерләү | агымдагы финанс елының 18 ноябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 4. | Биектау муниципаль районы Советы утырышында чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын карауга кабул итү һәм гавами тыңлаулар билгеләү турында карар раслау | агымдагы финанс елының 25 ноябренә кадәр | Биектау муниципаль районы Советы депутатлары |
| 5. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын карауга кабул итү һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турындагы норматив хокукый актны бастырып чыгару | агымдагы финанс елының 26 ноябренә кадәр | Биектау муниципаль районы Советының Оештыру бүлеге |
| 6. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү | агымдагы финанс елының 07 декабренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ Биектау муниципаль районы Советының Оештыру бүлеге белән берлектә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Гавами тыңлаулардан соң район бюджеты проекты өстендә эшләү һәм Биектау муниципаль районы Советы утырышында карау өчен проектны тәкъдим итү | агымдагы финанс елының 10 декабренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 8. | Биектау муниципаль районы Советы утырышында бюджет проектын карау һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджетын раслау | агымдагы финанс елының 14 декабренә кадәр | Биектау муниципаль районы Советы депутатлары |
| 9. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджетының чыгым йөкләмәләре реестрын формалаштыру | чираттагы финанс елының 16 гыйнварына кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |